БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 12 2025ел № 350

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2026-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Балтач муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауда, хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын ныгытуда барлык муниципаль һәм җәмәгать структураларның оешкан эшчәнлеген профилактикалауның күпдәрәҗәле системасын формалаштыру максатларында Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2026-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау» муниципаль программасын Кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль программаны җирле бюджетта каралган акчалар хисабына финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2025 елның «23» 12
350 номерлы карарына
кушымта

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2026-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау»
муниципаль программасы

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында 2026-2028 елларда хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау» (алга таба - Программа) |
| Заказчы - Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты;<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлеге;<br>«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ;<br>Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге;<br>Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге;<br>«Балтач үзәк район хастаханәсе» ДАСУ;<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;<br>Балтач районының «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ;<br>Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Балтачтагы бүлеге<br>Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җәзаларны үтәтү инспекциясе Федераль казна учреждениесының (ФКУ УИИ УФСИН по РТ) Балтач районы буенча филиалы |
| Программаның максаты | Хокук бозуларны профилактикалауны үстерү һәм камилләштерү, җәмәгать тәртибен ныгыту һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү, бу эшкә җәмәгать оешмаларын һәм халыкны җәлеп итү |
| Программаның бурычлары | Хокук бозуларны кисәтү, халыкка әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру һәм камилләштерү.<br>Иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза алган затларны һәм иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзага хөкем ителгән гражданнарны социаль адаптацияләү һәм реабилитацияләүне тәэмин итү. Халык арасында алкогольгә һәм наркотикларга бәйлелеккә каршы көрәшкә юнәлдерелгән хокук бозуларны, шулай ук икътисадый юнәлештәге җинаятьләрне профилактикалау эшен активлаштыру. Җәмәгать урыннарында кылынган хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау эшен оптимальләштерү.<br>Экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау. Административ участокларда хокук бозуларны профилактикалау эшен активлаштыру. |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары | 2026-2028 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары: | Җирле бюджет акчалары:<br>2026 ел - 5762400,00сум.<br>2027 ел - 6040500,00сум.<br>2028 ел - 6334900,00сум.<br>Искәрмә: Финанслау күләме фаразлау характерында була һәм, бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, аңа төзәтмәләр кертелергә мөмкин. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2028 елга, 2025 ел белән чагыштырганда, түбәндә күрсәтелгәннәрнең кимүенә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- 100 мең кешегә кылынган җинаятьләр саны;<br>- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында чагыштырма авырлыгы (удельный вес);<br>- элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең гомуми санында чагыштырма авырлыгы (удельный вес);<br>- урамнарда кылынган җинаятьләрнең гомуми санында чагыштырма авырлыгы (удельный вес);<br>- исерек хәлдә кылынган җинаятьләрнең гомуми санында чагыштырма авырлыгы (удельный вес). |

## 1. ПРОГРАММАНЫ РАСЛАУ КИРӘКЛЕГЕН НИГЕЗЛӘҮ

Хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау программасы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, федераль һәм республика программалары, шул исәптән җинаятьчелеккә каршы көрәш, наркотиклаштыруны профилактикалау, эш белән тәэмин ителмәгән халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм социаль яклау, яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү программалары нигезендә эшләнгән.

100 мең кешегә җинаятьчелек дәрәҗәсе:
2023 елның 12 аенда 645,1 җинаять,
2024 елның 12 аенда - 548,1,
2025 елның 9 аенда - 478,1 җинаять туры килә

Шул исәптән:
- авыр булмаган җинаятьләр:
2023 елның 12 аенда 258,7 җинаять булган,
2024 елның 12 аенда-283,2,
2025 елның 9 аенда – 70.

- уртача авырлыктагы җинаятьләр:
2023 елның 12 аенда 164,3 җинаять булган,
2024 елның 12 аенда – 121,8,
2025 елның 9 аенда – 25.

- авыр җинаятьләр:

2023 елның 12 аенда 222,1 җинаять булган,

2024 елның 12 аенда – 134,

2025 елның 9 аенда – 62.

- аеруча авыр җинаятьләр:
2023 елның 12 аенда 0 җинаять булган,
2024 елның 12 аенда - 9,1,
2025 елның 9 аенда - 1.

2023 елда исерек хәлдәге затларга карата кузгатылган җинаять эшләре буенча тикшерелгән җинаятьләр саны 49 дан 44 кә кадәр кимегән.

2024 елда 44 тән 50 гә арту күзәтелә.

2025 елда 9 айда 28 кеше тәшкил итә.

2023 елның 12 аенда 18 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, 2024 – 21, 2025 елның 9 аенда – 14.

Исерек килеш юл-транспорт һәлакәте ясаучылар 2023 елда – 2, 2024 – 3, 2025 елның 9 аенда – 1.

2023 елда мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә җинаятьләр саны - 90 (шулардан 52-мошенниклык, 28-банк карталарыннан урлау),

2024 - 93 (59-мошенниклык, 11-банк карталарыннан урлау, 27-компьютер мәгълүматына хокуксыз керү),

2025 (9 ай) – 57 (30 - мошенниклык, 7- банк карталарыннан урлау, 19 - компьютер мәгълүматына хокуксыз керү).

Узган анализ күрсәткечләренә, 2023 - 2025 еллар дәвамында районда оператив хәлнең төп үсеш тенденцияләренә, аның сыйфат һәм сан ягыннан үзгәрешләренә нигезләнеп, алдагы елларда оператив хәлнең төп үсеш тенденцияләрен фаразларга мөмкинлек бирә. Башкарылган нәтиҗәләр районда криминоген хәл тамырдан үзгәрүләр кичермәячәк дип фаразларга мөмкинлек бирә. Әмма безгә 2026-2028 елларда җинаятьләр саны арту тенденциясен, шул исәптән авыр җинаятьләр категориясенә керүче җинаятьләрнең, киму ягына үзгәртергә кирәк.

Милек җинаятьләре саны, нигездә, шәхси мөлкәтне урлау хисабына бераз артырга мөмкин. Шәхескә каршы аерым төр җинаятьләр динамикасы тенденцияләрен билгеләү дә шактый катлаулы. Әмма шәхескә каршы авыр һәм аеруча авыр җинаятьләрнең артуы көтелми. Аларның саны узган ел дәрәҗәсеннән артмаска тиеш.

Җәмгыять һәм дәүләт тарафыннан адекват профилактик каршы тору булмаган эчүчелекнең киң таралуы җинаятьчелек торышына йогынты ясый торган җитди фактор булып кала бирә.

Ирешелгән нәтиҗәләрне ныгыту һәм җинаятьчелеккә каршы торуның нәтиҗәлелеген арттыру өчен бу юнәлештә бердәм алымны дәвам итү һәм гамәлләрне координацияләү таләп ителә.

Хокук бозуларны профилактикалауның бөтен системасы эшенең нәтиҗәлелеге киму озак вакытка сузылачак һәм халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге тискәре нәтиҗәләргә алдагы елларда да йогынты ясаячак.

Болар барысы да хокук бозуларны профилактикалау проблемаларын хәл итүдә программалы-максатчан алымны киләчәктә куллану кирәклеген аңлата.

## 2. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Программаны тормышка ашыруның максаты - Балтач муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча эшчәнлекне камилләштерү һәм җәмәгать тәртибен саклау.

Программаның максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү таләп ителә:

- Балтач муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү;
- балигъ булмаганнар белән эшләүнең инновацион формаларын һәм ысулларын (методларын) куллану, балаларга һәм яшьләргә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирүне активлаштыру һәм камилләштерү;
- иректән мәхрүм итү урыннарыннан хөкем ителүчеләрне азат итүгә әзерләүне оештыру;
- җәмәгать урыннарында хокук тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү, җинаятьләрне ачу өчен җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлеген оештыру һәм заманча техник чаралар кертү;
- Балтач муниципаль районының торак пунктлары урамнарында хокук тәртибен тәэмин итү;
- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауның яңа формаларын һәм алымнарын эшләү.

Программаның бурычларын хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

- Балтач муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү;
- балигъ булмаганнар һәм яшьләр арасында җинаятьләрне кисәтү, аларны әхлакый тәрбияләүне активлаштыру һәм камилләштерү;
- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны һәм иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән гражданнарны, шул исәптән балигъ булмаганнарны һәм яшьләрне яңадан социальләштерү;
- җәмәгать урыннарында һәм урамнарда хокук бозуларны профилактикалау;
- тискәре тенденцияләрне үз вакытында ачыклау, муниципаль районда барлыкка килә торган милләтара һәм конфессияара вөзгыятьнең үсешен фаразлау һәм комплекслы анализ үткәрү, тиешле тәкъдимнәр эшләү һәм кертү.

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрне кулланырга тәкъдим ителә:

- җинаятьләр саны (динамикасы);
- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында чагыштырма авырлыгы (удельный вес);
- элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санында чагыштырма авырлыгы (удельный вес);
- урамнарда һәм җәмәгать урыннарында кылынган җинаятьләрнең теркәлгән җинаятьләрнең гомуми санында чагыштырма авырлыгы (удельный вес).

Программаны гамәлгә ашыруның гомуми вакыты 2026-2028 елларга исәпләнгән.

## 3. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ НИГЕЗЛӘҮ

Балтач муниципаль районы бюджеты хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме 18149100,00 сум тәшкил итә.

| Ел | Җирле бюджет акчалары |
|---|---|
| 2026 | 5762400,00 |
| 2027 | 6040500,00 |

| | |
|---|---|
| 2028 | 6334900,00 |
| Барлыгы: | 18137800,00 |

Программаның чараларын гамәлгә ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны файдалану күздә тотыла.

## 4. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Ел саен Программаның чараларына максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, Программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын аныклый торган, чараларны үтәү өчен җаваплы җирле үзидарә органнарыннан, ведомстволардан һәм учреждениеләрдән Программаның үтәлеше турында белешмәләр соратып ала торган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Программаның үтәлешен планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияләүне һәм гомуми контрольне гамәлгә ашыра.

Программаны гамәлгә ашыру, чараларны үтәү вакытларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеген үз эченә алган ел саен була торган план нигезендә гамәлгә ашырыла

Чараларны финанслау, аларны үтәү вакытларын күрсәтеп, структур бүлекчәләр һәм муниципаль учреждениеләр аша башкарыла.

Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы башкаручылар муниципаль заказчыга – Программаның координаторына квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 10 нчы көненә кадәр чараларның үтәлеше һәм чараларны башкаручыларга муниципаль бюджеттан бүлеп бирелә торган файдаланылган акча турында арта баручы нәтиҗә белән һәм гомумән хисап елы өчен мәгълүмат бирәләр.

Программаны гамәлгә ашыруның барышы һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап (алга таба - еллык хисап) башкаручылар белән берлектә Балтач район башкарма комитеты тарафыннан, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Программа буенча йомгаклау мәгълүматын формалаштыру һәм хисап елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр Балтач муниципаль районы башлыгына һәм Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрү өчен төзелә.

Еллык хисап түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- хисап чорында ирешелгән төгәл (конкрет) нәтиҗәләр;
- билгеләнгән вакытларда башкарылган һәм башкарылмаган (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеге;
- Программаны тормышка ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;
- бюджет ассигнованиеләреннән һәм чараларны үтәү өчен башка акчалардан файдалану турында белешмәләр;
- Программага җаваплы башкаручы тарафыннан кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат;
- башка мәгълүмат.

Программага үзгәрешләр кертү Программа чараларының җаваплы башкаручысы тарафыннан, яисә билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте йөкләмәләрен үтәү йөзеннән гамәлгә ашырыла.

Балтач муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе утырышларында даими рәвештә финанс чараларын куллану һәм Программа чараларының үтәлешен тикшерү планлаштырыла.

## 5. ПРОГРАММАНЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ, СОЦИАЛЬ ҺӘМ ЭКОЛОГИК НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Программа чараларын үтәү түбәндәге мөмкинлекләрне бирәчәк:

- хокук бозуларны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттырырга, хокук бозуларны кисәтү буенча эшчәнлекне оештыруга профилактикалауның барлык субъектларын, җәмәгатьчелекне җәлеп итәргә;
- хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен норматив-хокукый җайга салуны тәэмин итәргә;
- закон бозмаучы гражданинның яшәү рәвешен формалаштыру өчен мәгълүмат-пропаганда эшчәнлеген тулырак файдаланырга;
- халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен күтәрергә;
- авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр санын киметергә;
- урамнарда һәм башка җәмәгать урыннарында криминоген вәзгыятьне тотрыкландырырга (стабильләштерергә) һәм җинаятьләрнең әлеге төрен этаплап киметүне башларга;
- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган хокук бозуларны киметүне дәвам итәргә;
- элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган хокук бозуларны киметүне дәвам итәргә;
- район территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны, радикаль дини агымнарны, ксенофобияне, милли һәм раса каршылыкларын профилактикалау буенча җирле үзидарә органнарының эш формаларын һәм ысулларын камилләштерергә, район территориясендә этник дискриминациягә каршы торырга;
- террорчылык һәм экстремизм күренешләренең барлык фактларына карата түземсезлек, шулай ук толерант аң, башка этник һәм конфессиональ бергәлекләр вәкилләренә уңай карап формалаштыру;
- яшьләр арасында этникара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгытырга һәм үстерергә;
- район халкы арасында интернационализм, татулык, милли һәм дини түземлелек культураларын җәелдерергә.

**"ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА 2026-2028 ЕЛЛАРГА ХОКУК БОЗУЛАРНЫ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ТӘРТИБЕН САКЛАУ" МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ФИНАНСЛАУ**

| Төп чараларның исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, берәмлек | Индикаторларның әһәмияте | | | | Район бюджеты акчалары исәбеннән финанслау, (мең сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025(база) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Максат: Балтач муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү һәм җәмәгать тәртибен саклау | | | | | | | | | | |
| 1нче бурыч: Балтач муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү | | | | | | | | | | |
| 1.1. Массакүләм мәгълүмат чараларында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, зарарлы гадәтләрнең зарарлы булуын, яшьләрне рухи кыйммәтләргә юнәлтү һәм патриотизм пропагандалау, яшьләр арасында җинаятьчелек, наркомания һәм токсикомания, балаларның юл-транспорт травматизмы проблемалары буенча аңлату эшләре үткәрү. | КДНиЗП, опека һәм попечительлек секторы, «Хезмәт» газетасы редакциясе (килешү буенча), «Кайтаваз» радиосы, «Мәгариф идарәсе» МКУ, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), "Балтач РҮХ" ДАССУ( килешү буенча), | 2026-2028 квартал саен | 10,0мең кешегә кылынган җинаятьләр саны (берәмлек) | 51 | 50 | 49 | 48 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2.Россия Федерациясенең миграция законнарын бозуларны ачыклау буенча чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар яшәгән урыннарны, чит ил эшче көче кулланыла торган объектларны максатчан тикшерүне оештыру. Әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудырган наркомания, йогышлы авырулар белән авыручы чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны ачыклау буенча Сәламәтлек саклау учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру. | Федераль миграция хезмәте идарәсе, ТР Балтач РБК, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Авыл һәм шәһәр җирлекләре башкарма комитетлары, «Балтач район үзәк хастаханәсе» ДАССУ | 2026-2028 квартал саен | | | | | | - | - | - |
| 1.3.Балтач муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру. | Авыл һәм шәһәр җирлекләре башкарма комитетлары | 2026-2028 ел саен | | | | | | - | - | - |
| 1.4. Күпфатирлы йортларның подъездларында һәм йорт яны территорияләрендә, урамнарда, скверларда, паркларда һәм башка җәмәгать урыннарында видеокамералар, яктырту приборлары урнаштыру. | Авыл һәм шәһәр җирлекләре башкарма комитетлары | 2026-2028 ел саен | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.5. Җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турындагы гамәлдәге законнар кысаларында студент һәм эшче яшьләр халык дружиналары эшен оештыру<br>- "ФОРПОСТ" МБУның иң актив катнашучыларын, ирекле халык дружиналарын, иҗтимагый формированиеләрне, юл хәрәкәте иминлеге яшь инспекторларын билгеләү буенча ел саен үткәрелә торган чара үткәрү һәм аларны Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенең Рәхмәт хаты һәм кыйммәтле бүләк белән бүләкләү | ТР Балтач РБК, ОДМС, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2026-2028 ел саен | | | | | | - | - | - |
| 2 нче бурыч: балигъ булмаганнар белән эшләүнең инновацион формаларын һәм ысулларын куллану, активлаштыру һәм камилләштерү балаларга һәм яшьләргә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү | | | | | | | | | | |
| 2.1. Сәламәт яшәү рәвешенә тарту максатында кич, ял һәм бәйрәм көннәрендә яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ял һәм спорт учреждениеләренә баруын оештыру | «Мәгариф идарәсе"МКУ, ОДМС, КДНиЗП, опека һәм попечительлек секторы, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2026-2028 квартал саен | Балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең ,тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санының чагыштырма күләме | 1,3 | 1,3 | 1,2 | 1,1 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2.Балалар күзәтүчесезлеге һәм җинаятьчелек, социаль ятимлек проблемалары буенча ведомствоара киңәшмәләр, утырышлар, «түгәрәк өстәлләр» уздыру, шул исәптән төрле дәрәҗәдәге депутатлар, иҗтимагый оешмалар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашында | ТР Балтач РИК, «мәгариф идарәсе» МКУ, ОДМС, КДНиЗП, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), ОСЗ (килешү буенча) | 2026-2028 ел саен | (процентлар) | | | | | - | - | - |
| 2.3.Ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, аз тәэмин ителгән, имин булмаган һәм күпбалалы гаиләләрдәге, шулай ук балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә исәптә торучы балалар өчен «Романтик» балаларның җәйге сәламәтләндерү лагере МУга түләүсез юлламалар квоталауны тәэмин итү | ТР Балтач район башкарма комитеты | 2026-2028 ел саен | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.4.Балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү эшен оештыру, яшүсмерләрне һәм яшьләрне формаль булмаган яшьләр берләшмәләренә җәлеп итүне кисәтү эшен үткәрү:<br>- сугышчы-интернационалистлар көненә багышланган район чарасын үткәрү;<br>- хәрби хезмәткә чакырылучылар өчен район чарасы үткәрү;<br>- Бөек Ватан сугышында Җиңүгә багышланган район чараларын үткәрү;<br>- ел саен район спартакиадаларын, «иң яхшы профилактика отряды» конкурсын уздыру, җиңүчеләрне бүләкләү;<br>- Балтач муниципаль районы уку йортларында хәрби хезмәт нигезләре буенча әзерлек узучы укучылар белән укыту-кыр җыеннарын оештыру һәм үткәрү;<br>- җәйге туристлык слетын оештыру һәм уздыру;<br>- «Школа выживания», «Россия патриотларын үстерәбез», «Ватанны сакларга әзер» республика ярышларында катнашу;<br>- физкультура-спорт һәм хәйрия спартакиадалары, ярышлар, фестивальләр һәм конкурслар, конкурсларда җиңүчеләргә һәм катнашучыларга бүләкләр алу өчен мәҗбүри рәвештә акча бүлеп бирелә | «Мәгариф идарәсе» МКУ, ОДМС, мәдәният бүлеге, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча)<br>ТР Балтач РБК, ОДМС, мәдәният бүлеге, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча)<br>«Мәгариф идарәсе» МКУ, ОДМС, мәдәният бүлеге, ВК<br>«Мәгариф идарәсе» МКУ, ОДМС, мәдәният бүлеге,Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча)<br>«Мәгариф идарәсе» МКУ, ОДМС, Эчке эшләр министрлыгы( килешү буенча ОДМС, "мәгариф идарәсе"МКУ | 2026-2028 ел саен | | | | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.5. Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны ачыклау буенча чаралар үткәрү, балаларны тиешле дәрәҗәдә тәрбияләмәүче ата-аналарга карата профилактик эш оештыру (максатчан рейдлар үткәрү, административ җаваплылыкка тарту, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү өчен материаллар җыю, профилактик эш үткәрү, алкогольгә бәйлелектән дәвалауны оештыру) | КДНиЗП, опека һәм попечительлек секторы, "мәгариф идарәсе" МКУ, ОДМС, ОСЗ (килешү буенча) | 2026-2028 квартал саен | | | | | | - | - | - |
| 2.6.Наркотиклар куллануны, эчкечелекне, алкоголизмны һәм тәмәке тартуны кисәтү һәм булдырмау максатында мәгариф оешмаларында укучылар өчен семинарлар, лекцияләр. Укучыларга һәм ата-аналарга брошюралар әзерләү һәм тарату. | "Мәгариф идарәсе" МКУ, ОДМС, КДНиЗП, ОСЗ (килешү буенча) | 2026-2028 квартал саен | | | | | | - | - | - |
| 2.7.«Балтач РБК мәгариф идарәсе» МКУ каршында авыр тормыш хәлендә калган балалар белән эшли торган психологик-педагогик хезмәт оештыру. | «Мәгариф идарәсе» МКУ, ОСЗ (килешү буенча) | 2026-2028 квартал саен | | | | | | 2284,6 | 2260,4 | 2260,4 |
| 2.8.Балаларның юл-транспорт травматизмын профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар үткәрү. | «Мәгариф идарәсе» МКУ,ОДМС, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2026-2028 квартал саен | | | | | | - | - | - |
| 2.9. Авыр тормыш хәлендә булган затларга аларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү. | ОСЗ | 2026-2028 квартал саен | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.10. Авыр тормыш хәлендә калган, шул исәптән медицина максатларында наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр кулланучы затларга югалтылган социаль элемтәләрне һәм функцияләрне торгызу буенча чаралар үткәрү. | «Балтач район үзәк хастаханәсе" ДАССУ | 2026-2028 квартал саен | | | | | | | | |
| 2.11. Балигъ булмаганнарны укудан буш һәм каникул вакытында эш белән тәэмин итүне оештыру | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге | 2026-2028 квартал саен | | | | | | | | |
| 2.12. 16 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны эшкә урнаштыруда, шул исәптән махсуслаштырылган мәшгульлек программалары кысаларында (вакытлыча эшкә урнаштыру, җәмәгать эшләре)ярдәм итү | «Мәгариф идарәсе" МКУ | 2026-2028 ярты елга бер тапкыр | | | | | | | | |
| 2.13 җәмәгать тәрбиячеләре белән эшне оештыру | КДН, Авыл һәм шәһәр җирлекләре башкарма комитетлары | 2026-2028 ярты елга бер тапкыр | | | | | | | | |
| 3 нче бурыч: административ участокларда хокук бозуларны профилактикалау, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар белән эшләү | | | | | | | | | | |
| 3.1. Гражданнарга карата хокук бозулар һәм социаль мошенниклыкны профилактикалау буенча башка мәгълүмат, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә мошенниклык кылганда гамәлдә булу тәртибе турында хәтерлекләр (листовкалар) әзерләү һәм халык арасында тарату | Балтач РБК, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), ОСЗ «мәгариф идарәсе» МКУ (килешү буенча) | 2026-2028 ел саен | | 18,5 | 18,4 | 18,3 | 18,2 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.2. Ел саен полиция участок уполномоченныйлары катнашында «Танышырга рөхсәт итегез»акциясен үткәрү. | Авыл һәм шәһәр җирлекләре башкарма комитетлары, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча )) | 2026-2028 ел саен | | | | | | - | - | - |
| 3.3. Җәмәгать тәртибен тәэмин итү, гражданнарның шәхси иминлеген тәэмин итү һәм аларның милкен яклау эшен оештыру (ОПОП) | БМР башлыгы каршындагы Коррупциягә каршы көрәш советы | 2026-2028 ел саен | | | | | | 2668,3- | 2935,1- | 3229,5- |
| 3.4. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, алкоголизм һәм наркомания белән интегүче затлар белән профилактик эш оештыру, эшкә урнашуда ярдәм күрсәтү. | ТР Балтач РБК, «Балтач РҮХ" ДАССУ (килешү буенча), УФСИН филиалы (килешү буенча) | 2026-2028 квартал саен | | | | | | - | - | - |
| 3.5. Муниципаль берәмлек предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә җәмгыятьтән аерылмыйча җәзага хөкем ителгән затлар өчен эш урыннарын мәҗбүри квоталауны оештыру. | Татарстан Республикасы Балтач РБК, УФСИН филиалы (килешү буенча), предприятиеләр һәм учреждениеләр | 2026-2028 ел саен | | | | | | - | - | - |
| 4 нче бурыч: урамнарда һәм җәмәгать урыннарында хокук тәртибен тәэмин итү | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1Яшьләрнең хокук саклау хәрәкәтен үстерү, "ФОРПОСТ" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләрен, ирекле халык дружиналарын, җәмәгать формированиеләрен, юл хәрәкәте иминлегенең яшь инспекторларын, җинаять һәм административ законнарны, юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнү, аларның матди-техник базасын ныгыту секцияләрен һәм түгәрәкләрен булдыру һәм аларга ярдәм итү эшен оештыру. | ТР Балтач РБК, "мәгариф идарәсе" МКУ, ОДМС, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Авыл һәм шәһәр җирлекләре башкарма комитетлары | 2026-2028 квартал саен | Урамда кылынган теркәлгәннәрнең гомуми санында җинаятьләрнең чагыштырма күләме (процентлар) | 13,5 | 13,4 | 13,3 | 13,2 | 690,8 | 845,0 | 845,0 |
| 4.2. Җәмәгать тәртибен саклауда ирекле катнашучы затларның уңай эш тәҗрибәсен һәм фидакарь гамәлләрен массакүләм мәгълүмат чараларында пропагандалау. | «Хезмәт» газетасы редакциясе (килешү буенча), «Кайтаваз» радиосы, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2026-2028 ел саен | | | | | | - | - | - |
| 4.3. Объектларда һәм янәшәдәге территорияләрдә видеокүзәтү урнаштыру буенча шәхси эшмәкәрләр һәм оешмалар белән эшне оештыру. | Авыл һәм шәһәр җирлекләре башкарма комитетлары, Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2026-2028 квартал саен | | | | | | - | - | - |
| 4.4. Видеокүзәтү системасына хезмәт күрсәтү | Авыл һәм шәһәр җирлекләре башкарма комитетлары | 2026-2028 ай саен | | | | | | - | - | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| БАРЛЫГЫ | | 5643,7 | 6040,5 | 6334,9 |

*> Кулланылган кыскартылулар исемлеге

ТР Балтач РБК – Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты

ОМВД – Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлеге

ОДМС – Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге

ОК – Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге

"Мәгариф идарәсе" МКУ - МКУ «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Мәгариф идарәсе»

«Балтач үзәк район хастаханәсе» ДАССУ **- «Балтач үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе**

ОСЗ - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге

ЦЗН - Балтач районының "халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" дәүләт казна учреждениесе

УФМС бүлеге - Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Балтач идарәсе бүлеге

УФСИН филиалы – "Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе" Федераль казна учреждениесенең Балтач районы филиалы

ДЮСШ –Балтач муниципаль районының «Балалар–яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

КДНиЗП – Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе

ВК – хәрби комиссариат

МБ – җирле бюджет

ВБ – бюджеттан тыш